СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 168 от 13.12.2022
На № __________ от ____________

# КАРАР

Хәрби хезмәт үтү яки Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү чорына арендаторларга муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү турында

Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында” 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына Саба муниципаль районы муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил иткән мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, аларда арендаторлар булып физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар тора, аларда юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган бер үк физик зат тора, күрсәтелгән физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр яисә физик затлар, юридик затның гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган физик зат, Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында” 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә “Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында” 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты (алга таба - Федераль закон) нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт узучы затлар булса, яки Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән булсалар, аларны түбәндәгеләр белән тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектереп тору (алга таба - аренда түләвен кичектерү);

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлеге.

2. Әлеге карарның 1 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен кичектерү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан аренда түләвен кичектереп тору чорында шартнамә буенча арендалана торган мөлкәттән файдаланмау;

арендатор, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен, яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзү турында хәбәрнамәнең күчермәләрен яки  федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырылган, алар белән күрсәтелгән контрактлар төзелгән Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт күчермәләрен куеп, аренда түләвен кичектереп тору турында хәбәрнамә җибәрә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән арендага алучыга әлеге карарның 4 пункты нигезендә исәпләнә торган чорга аренда түләвен кичектереп торыла;

аренда түләве буенча бурыч аренда түләвен  кичектереп тору вакыты тәмамланган көннән алып, этаплап, айга бер тапкырдан да ешрак булмаган, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган күләмдә өстәмә килешү нигезендә түләнергә тиеш;

аренда түләвен кичектерү белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый.

3. Әлеге карарның 1 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда шартнамәсен өзү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

арендатор, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә җибәрә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен,  Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзү турында хәбәрнамәнең күчермәләрен, күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турындагы контрактның күчермәләрен кушып;

аренда шартнамәсе аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә алган көннән соң өзелергә тиеш;

чит акчалардан файдаланган өчен процентлар, штрафлар яки аренда шартнамәсен өзүгә бәйле рәвештә башка җаваплылык чаралары

кулланылмый(шул исәптән, аренда шартнамәсендә мондый чаралар каралган очракларда).

4. Аренда түләвен кичектерү срогы 90 көнгә озайтылган мобилизация срогы буларак исәпләнелә һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның хастаханәләрдә, госпитальләрдә, стационар шартларда мобилизация чорында бурычларны үтәгәндә алынган гарипләнүдән (яраланудан, җәрәхәтләнүдән, контузиядән) яки авырудан дәвалануда булган вакытка озайтыла, ә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат билгесез югалган дип танылган очракта – аны билгесез юк дип тану турында суд карары гамәлдән чыгарылганчыга кадәр яисә суд аны вафат дип игълан иткәнче озайтыла.

Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат һәлак булган (вафат булган) очракта, ул мобилизация чорында йә күрсәтелгән чордан соң үлгән булса, мобилизация чорындагы гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яисә мобилизация чорында алынган авыру нәтиҗәсендә, шулай ук аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип танылган очракта, кичектерү чорына аренда түләве алынмый.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалид дип тануга, үлемгә китергән гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яисә авыру сәбәбе мобилизация чоры белән хәрби-табиб комиссияләре һәм (яисә) федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына, муниципаль предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә хуҗалык алып бару хокукында яисә муниципаль предприятиеләргә оператив идарә итү хокукында яисә физик затлар алар буенча арендага алучылар булган муниципаль учреждениеләргә оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, аларда арендаторлар булып физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар тора, аларда юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган бер үк физик зат тора, күрсәтелгән физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр яисә физик затлар, юридик затның гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган физик зат, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты (алга таба - Федераль закон) нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт узучы затлар булса, яки яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән булсалар, аларны түбәндәгеләр белән тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектереп торырга;

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлеге.

6. Әлеге карарның 5 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен кичектереп тору әлеге карарның 2 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карарның 5 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда шартнамәсен өзү әлеге карарның 3 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов